ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23 апрель 2021 ел № 2863

Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 31 статьясы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Законы, шәһәр Уставы, Россия Транспорт министрлыгының «Автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү тәртибен раслау турында» 2019 елның 5 июнендәге 167 номерлы Приказы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Авыр транспорт чаралары китергән зыянны каплау кагыйдәләрен раслау турында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын үзгәртү һәм үз көчен югалтуны тану турында» 2020 елның 31 гыйнварындагы 67 номерлы Карары, Башкарма комитетның 2021 елның 3 мартындагы 1441 номерлы карары белән расланган муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеге нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымтада каралганча расларга.

2. 2019 елның 27 февралендә, 2019 елның 6 мартында «Челнинские известия» газетасының 14 нче, 16 нчы саннарында бастырып чыгарылган, 2019 елның 28 февралендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырылган «Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 25 февралендәге 977 номерлы Башкарма комитет карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны

«Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 23 апрелендәге
2863 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең
җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында
авыр һәм (яки) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәтенә
махсус рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламенты

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – регламент) җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар: транспорт чаралары хуҗалары – физик һәм юридик затлар (алга таба – гариза бирүче).

1.3. Муниципаль хезмәт Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә.

Муниципаль хезмәтне башкаручы – Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе (алга таба – идарә).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт.

Идарәнең урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт, 414, 419 кабинетлар.

Башкарма комитетның эш графигы:

дүшәмбе-җомга 8.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр.

төшке аш вакыты: 12.00 дән 13.00 сәгатькә кадәр.

ял көннәре: шимбә, якшәмбе.

Идарәнең белешмә телефоннары: 30-57-55, 30-57-95, 30-57-94, 30-57-99.

Башкарма комитет бинасына керү шәхесне раслаучы документлар буенча.

1.3.2. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге рәсми сайтының адресы: https://nabchelny.ru.

Идарәнең электрон почта адресы: ik-414@mail.ru

1.3.3. Муниципаль хезмәт турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен, Башкарма комитет бинасында урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган муниципаль хезмәт турында мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында;

3) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында https://gosuslugi.ru;

4) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында https://uslugi.tatar.ru;

5) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә, Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – ЕГИССО) операторы билгеләгән форматлар нигезендә, ЕГИССОдан файдалану юлы белән;

6) Башкарма комитетта (идарәдә):

- телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон аша;

- язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә – почта аша кәгазьдә, электрон почта: kancel.chelny@tatar.ru аша электрон формада.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә башкарыла:

1) «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 181-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 02.08.2010, № 31, ст. 4179);

2) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 131-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 06.10.2003, № 40, ст. 3822);

3) «Россия Федерациясендә автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 257-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 12.11.2007, № 46, ст. 5553);

4) «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 02.08.2010, № 31, ст. 4179);

5) «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 11.04.2011, № 15, ст. 2036);

6) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Авыр транспорт чаралары китергән зыянны каплау кагыйдәләрен раслау турында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын үзгәртү һәм үз көчен югалтуны дип тану турында» 2020 елның 31 гыйнварындагы 67 номерлы Карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 67 номерлы карары);

7) Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «Автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү тәртибен раслау турында» 2019 елның 5 июнендәге 167 номерлы Приказы (алга таба – 167 номерлы Приказ);

8) Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «Автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәтен оештыруга таләпләрне раслау турында» 2020 елның 31 августындагы 343 номерлы Приказы (алга таба – 343 номерлы Приказ);

9) «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 45-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, 03.08.2004, № 155-156,);

10) Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Законы (алга таба – 43-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, 11.08.2009, № 160);

11) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Вәкиллекле органының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – шәһәр Уставы), (Челнинские известия, № 235 – 237, 10.12.2005, № 249 – 250, 30.12.2005);

12) Башкарма комитетның 2021 елның 3 мартындагы 1441 номерлы карары белән расланган муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеге (алга таба – муниципаль хезмәтләр исемлеге);

13) Башкарма комитетның 2017 елның 11 июлендәге 674-р номерлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе

турында нигезләмә (алга таба – идарә турында нигезләмә);

14) Башкарма комитетның 2020 елның 25 февралендәге 101-р номерлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр).

1.5. Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) – муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос (3 нче кушымта);

2) авыр транспорт чарасы – йөк белән яки йөксез килеш һәм (яки) күчәргә төшкән авырлык массасы транспорт чарасының Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән рөхсәт ителгән массасыннан һәм (яки) күчәргә төшкән рөхсәт ителгән авырлыгыннан артып киткән транспорт чарасы;

3) эре габаритлы транспорт чарасы – йөк белән яки йөксез килеш габаритлары Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән, рөхсәт ителгән габаритлардан артып киткән транспорт чарасы;

4) йөк урыны – ташу өчен кабул ителә торган һәм контейнерда, тарада (төргәктә), транспорт пакетында, цистернада, салына торган кузовта булган бер материаль объект;

5) техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның бу мәгълүматларны кертүгә нигез булган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата);

6) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны (алга таба – КФҮнең ерактагы эш урыны) – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Яр Чаллы шәһәрендә төзелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең (алга таба – КФҮ) территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпнең исеме | Стандартка таләпләрнең эчтәлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен хокукый нигезләр |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәтнең исеме | Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү | муниципаль хезмәтләр исемлеге;<br>167 номерлы Приказның<br>VI бүлеге |
| 2.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның исеме | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты исеменнән шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | Уставның 41 статьясы; |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | 1) Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт (1 нче кушымта);<br>2) Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе (2 нче кушымта) | 257-ФЗ номерлы<br>Федераль законның<br>31 статьясының 10 пункты |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы | 1) гариза теркәлгәннән соң 11 эш көне, әгәр автомобиль юлы хуҗасының гына килештерүе таләп ителсә;<br>2) транспорт чарасы маршрутын Дәүләт автоинспекциясе белән килештерергә кирәк булган очракта, гариза теркәлгән датадан башлап 15 эш көне эчендә;<br>3) авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыру өчен автомобиль юлларының техник торышын бәяләү, аларны ныгыту яки автомобиль юлларын, аларның участокларын, шулай ук автомобиль юлын кисеп үтүче корылмаларны һәм инженерлык коммуникацияләрен төзекләндерү буенча махсус чаралар күрү | 167 номерлы Приказның<br>40, 41 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | таләп ителгән очракта – махсус рөхсәт бирү срогы күрсәтелгән чараларны үткәрү срогына арта;<br>4) гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерү өчен җибәрелә торган авыр һәм (яки) эре габаритлы транспорт чараларын, шулай ук телеканалларның, радиоканалларның һәм башка тапшыруларның махсус транспорт чараларын (йөкләре видеога төшерүне үткәрү өчен кирәкле җиһазларны тәшкил иткән төп һәм ярдәмче транспорт чарасыннан торган һәм видеога төшерү һәм трансляцияләрне үткәрүгә юнәлдерелә торган мобиль энергетик комплекслардан торган күчмә телевизион станцияләр) үткәрү турында гариза ул кергән датадан башлап бер эш көне эчендә | |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен килештерү таләп ителә торган Башкарма комитет структур бүлекчәләренең, дәүләт хакимияте органнарының һәм аларның структур бүлекчәләренең исемлеге | 1. Идарә (маршрутны җирле әһәмияткә ия автомобиль юлының хуҗасы буларак килештерә).<br>2. РФ ЭЭМ ЮХИДИ территориаль идарәсе, авыр транспорт чарасы хәрәкәте өчен таләп ителгән очракларда:<br>1) автомобиль юлларының аерым участокларын ныгыту;<br>2) транспорт чарасы маршруты чикләрендә автомобиль юлларын һәм аларны кисеп үтүче корылмаларны һәм инженерлык коммуникацияләрен төзекләндерү буенча махсус чаралар күрү;<br>3) авыр һәм (яки) эре габаритлы транспорт чарасының маршруты буенча юл хәрәкәтен оештыруны үзгәртү;<br>4) юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү таләпләре буенча башка транспорт чаралары хәрәкәтенә карата чикләүләр кертү | 167 номерлы Приказның 15 пункты |
| 2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен законнар яки башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле һәм гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге | 1) гариза (3 нче кушымта);<br>2) гариза бирүченең яисә гариза бирүче вәкиленең шәхесен таныклаучы документ;<br>3) транспорт чарасы хуҗасы вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ;<br>4) аннан файдаланып бару планлаштырыла торган һәр транспорт чарасы документларының күчермәсе (транспорт чарасы | 167 номерлы Приказның 6, 9 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | паспорты яки транспорт чарасын теркәү турында таныклык, үзйөрешле машина паспорты);<br>5) йөкне (йөк булганда) урнаштыру сурәте төшерелгән авыр һәм (яки) эре габаритлы транспорт чарасының (автопоезд) схемасы (йөк булганда). Схемада йөк ташуда катнашырга планлаштырыла торган транспорт чарасы, аның йөк белән (йөк булганда) габаритлары, андагы күчәрләр һәм тәгәрмәчләр саны, күчәрләрнең һәм тәгәрмәчләрнең үзара урнашуы, күчәрләргә төшкән авырлыкны билгеләү һәм күчәр озынлыгы буенча авырлык тигез бүленмәгән очракта – аерым тәгәрмәчләргә бүлү, шулай ук йөк булган очракта – йөк габаритлары, транспорт чарасында йөкнең урнашуы, төяү биеклеге, салынып торуы (булган очракта) (профильдә, арттан күренеше), йөкне беркетү ысуллары, урыннары сурәтләнә;<br>6) күрсәтелгән йөкне транспортта ташуга техник таләпләр турында мәгълүматлар (йөк ташыган очракта) – йөкне әзерләүченең, җитештерүченең мәгълүматлары, йөкнең авырлык габариты параметрлары турында мәгълүматны үз эченә алган эксплуатация документлары;<br>7) махсус рөхсәт биргән өчен дәүләт пошлинасын түләүне раслаучы түләү документының күчермәсе (дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында Дәүләт мәгълүмат системасында булган дәүләт пошлинасын түләү турында мәгълүмат булганда, түләү документының күчермәсе таләп ителми);<br>8) гариза бирү вакытына гамәлдә булу срогы чыкмаган элек бирелгән махсус рөхсәт күчермәсе – әлеге транспорт чарасына гамәлдәге махсус рөхсәт булганда, бер муниципаль берәмлек чикләрендә марттан сентябрьгә кадәрге чорда, үзе йөреп, эре габаритлы авыл хуҗалыгы техникасы (комбайн, трактор) хәрәкәтенә гариза кабат бирелгән очракта | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле һәм, алар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиеш булу сәбәпле, гариза бирүче үз инициативасы буенча тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге | 1) Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан мәгълүматлар;<br>2) Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан мәгълүматлар | |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1) гариза әлеге гаризаны имзалау өчен вәкаләтләре булмаган зат тарафыннан имзаланган;<br>2) гаризада Транспорт министрлыгының 167 номерлы приказының 8 пунктында билгеләнгән мәгълүматлар юк;<br>3) гаризага теркәлә торган документлар Транспорт министрлыгының 167 номерлы Приказының 9, 10 пунктлары таләпләренә туры килми (Транспорт министрлыгының 167 номерлы Приказының 9 пунктының 4 һәм 5 пунктчаларында билгеләнгән очраклардан тыш) | 167 номерлы Приказның 8, 9 пунктлары |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Баш тарту өчен нигезләр:<br>1. билгеләнгән маршрут буенча махсус рөхсәт бирү буенча вәкаләтле органның вәкаләтләре булмау.<br>2. шәхси эшмәкәр яки юридик зат буларак дәүләт теркәве турындагы мәгълүмат гаризада күрсәтелгән тиешле мәгълүматка туры килми.<br>3. гаризада һәм документларда бирелгән мәгълүматлар транспорт чарасының һәм йөкнең техник характеристикаларына, шулай ук күрсәтелгән йөк ташуны гамәлгә ашыруның техник мөмкинлекләренә туры килми. | 167 номерлы Приказның 39 пункт |

4. бүленә торган йөкне ташу турында билгеләнгән таләпләр үтәлмәгән.

5. маршрутны килештергәндә автомобиль юлының, ясалма корылманың яки инженерлык коммуникацияләренең техник торышына, шулай ук юл хәрәкәте иминлеге таләпләренә бәйле рәвештә, билгеләнгән техник характеристикалы авыр һәм (яки) эре габаритлы транспорт хәрәкәтен гамәлгә ашыру мөмкин булмау билгеләнгән.

6. Гариза бирүченең ризалыгы юк:

1) автомобиль юлының техник торышын бәяләүне үткәрүгә;

2) автомобиль юлының техник торышын бәяләү нигезендә билгеләнгән һәм законнарда билгеләнгән очракларда, автомобиль юлын кисеп үтүче корылмаларны һәм инженерлык коммуникацияләрен төзекләндерү буенча махсус чаралар күрүгә;

3) автомобиль юлының техник торышын бәяләү нигезендә билгеләнгән һәм законнарда билгеләнгән очракларда, автомобиль юлларын ныгытуга яки автомобиль юлларын яисә аларның участокларын төзекләндерү буенча махсус чаралар күрүгә.

7. мондый эшләр гариза бирүче белән килештереп үткәрелгән һәм мондый түләүне раслый торган түләү документларының күчермәләрен тапшырмаган очракта, гариза бирүче автомобиль юлларының техник торышын бәяләү, аларны ныгыту өчен түләмәгән.

8. әгәр мондый эшләр гариза бирүче белән килештереп башкарылган һәм мондый түләүне раслый торган түләү документларының күчермәләрен тапшырмаган булса, гариза бирүче автомобиль юлларын, аларның участокларын, шулай ук автомобиль юлын кисеп үтүче корылмаларны һәм инженерлык коммуникацияләрен төзекләндерү буенча махсус чаралар күрү өчен түләмәгән.

9. гариза бирүче автомобиль юлларына авыр транспорт чарасы китерә торган зыянны каплау исәбенә түләү кертмәгән һәм мондый түләүне раслый торган түләү документларының күчермәләрен тапшырмаган.

| | | |
|---|---|---|
| | 10. гариза һәм документлар вәкаләтле органга факсимиль элемтәдән файдаланып җибәрелгән очракта, махсус рөхсәт бирелгән вакытка гаризаның һәм автопоезд схемасының, транспорт чарасын теркәү буенча таныкланган документларының төп нөсхәләре юк.<br>11. әгәр махсус проект һәм (яки) юл хәрәкәтен оештыру проектын эшләү таләп ителмәсә, автомобиль юллары хуҗаларының яки килештерүче оешмаларның килешүе юк.<br>12. махсус проект, юл хәрәкәтен оештыру проекты юк (кирәк булганда).<br>13. Транспорт министрлыгының 167 номерлы Приказының 9 пунктының 5 пунктчасы нигезендә гариза кабат бирелгән очракта, эре габаритлы авыл хуҗалыгы техникасы (комбайн, трактор) авыр йөк транспорт чарасы булып тора | |
| 2.10. Федераль законнарда, алар нигезендә кабул ителә торган башка норматив актларда каралган очракларда, муниципаль хезмәт күрсәтелүче гариза бирүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары | 1) дәүләт пошлинасы күләме – 1600 сум;<br>2) авыр транспорт чарасы китерә торган зыянны каплау исәбенә түләү күләме Башкарма комитетның 2011 елның 14 апрелендәге 1882 номерлы карары нигезендә билгеләнә | РФ Салым кодексының 333.33 статьясының 1 пунктының 111 пунктчасы;<br>257-ФЗ номерлы Федераль законның 31 статьясының 13 пункты |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Чират булганда, муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирү һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу – 15 минуттан артык түгел | |
| 2.12. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросын теркәү срогы, шул исәптән электрон формада | Гариза кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә. | 167 номерлы Приказның 13 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| 2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне кабул итү һәм аларның көтеп тору залына, андый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыруга, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен уңайлылыгын тәэмин итүгә таләпләр | 1) муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган бүлмәләрдә һәм биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен истә тотып урнаштырыла.<br>2) инвалидларга тәэмин ителә:<br>- муниципаль хезмәт күрсәтелә торган бинага, бүлмәгә тоткарлыксыз керү (керү һәм аннан чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү, шул исәптән кресло-коляскадан файдаланып);<br>- муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарда, бүлмәләрдә, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналар, бүлмәләр урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;<br>- күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе бозылган инвалидларны озатып йөрү һәм аларга муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарда, бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;<br>- инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, бүлмәләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөрткечләрне тиешенчә урнаштыру;<br>- ишетә һәм күрә торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны рельефлы-ноктаны Брайль шрифтында башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;<br>- закон нигезендә билгеләнә торган форма буенча һәм тәртиптә бирелә һәм махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булганда, муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, бүлмәләргә юл күрсәтүче этне кертү;<br>- муниципаль хезмәт күрсәтә торган оешмаларның хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга башка затлар белән | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясының 12 пункты,<br>«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| | бертигез дәрәҗәдә муниципаль хезмәттән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.<br>Әлеге пунктның 2 пунктчасында күрсәтелгән таләпләр бары тик файдалануга яңа тапшырылган яки реконструкцияләнгән, модернизацияләнгән объектларга һәм чараларга гына куела. | |
| 2.14. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алырлык булу һәм сыйфат күрсәткечләре, муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге | Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре:<br>1) бинаның җәмәгать транспортыннан һәркем файдалана алырлык зонада урнашуы;<br>2) кирәкле сандагы белгечләр, шулай ук документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган бүлмәләр булу;<br>3) мәгълүмат стендларында, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>4) инвалидларга муниципаль хезмәттән башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә файдалануга комачаулый торган каршылыкларны җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>1) документлар кабул иткәндә һәм документлар биргәндә чиратлар;<br>2) муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозулар;<br>3) муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затларның эш итүләренә (эш итмәвенә) шикаятьләр;<br>4) муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затларның тупас, игътибарсыз мөнәсәбәтенә шикаятьләр. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.15. Башка таләпләр, шул исәптән КФҮдә муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен һәм электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алучы башка таләпләр | Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда, муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи зат белән гариза бирүченең бер тапкыр хезмәттәшлек итүе күздә тотыла. Үзара хезмәттәшлек дәвамлылыгы регламент белән билгеләнә.<br>Муниципаль хезмәт КФҮдә, КФҮнең ерактагы эш урыннарында күрсәтелгәндә, консультация бирүне, документлар кабул итүне һәм бирүне КФҮ хезмәткәре гамәлгә ашыра. | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 29 статьясындагы 4 өлешнең 1 пункты |

3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге
һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шулай ук административ процедураларны КФҮдә үтәү үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара запрослар формалаштыру һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү һәм гариза бирүчегә бирү;

5) муниципаль хезмәтне КФҮ аша күрсәтү.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү

3.2.1. Гариза бирүче консультация алу өчен идарәгә шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Идарә белгече гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән тапшырыла торган документларның (аларның күчермәләренең) составы, формасы, эчтәлеге буенча һәм кирәк булганда гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы, эчтәлеге буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче яки ул вәкаләтләгән зат Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә (алга таба – эш кәгазҗләрен алып бару идарәсе) яки КФҮ, КФҮнең ерактагы эш урыны аша гариза бирә һәм регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыра.

КФҮнең ерактагы эш урыннары исемлеге регламентка 5 нче кушымтада бирелгән.

3.3.2. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гамәлгә ашыра:

1) гариза бирүченең яки аның вәкиленең шәхесен ачыклауны;

2) гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен тикшерүне (ышаныч язуы белән эш иткән очракта);

3) регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларның булуын тикшерү;

4) тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерүне (документларның күчермәләрен тиешенчә рәсмиләштерү, документларда бозып язулар, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм башка алдан килешенмәгән төзәтүләр булмау).

Кимчелекләр булмаган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гамәлгә ашыра:

1) бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасыннан файдаланып, гаризаны кабул итүне һәм теркәүне;

2) керә торган документларның теркәү карточкасын төзүне;

3) гариза бирүчегә, документларны кабул итү датасы турында билгеләп, гаризаның күчермәсен тапшыруны;

4) гаризаны һәм теркәлгән документларны карап тикшерү өчен, бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасы аша Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрүне.

Регламентның 2.8 пунктында каралган, документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булуы турында хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен аңлатып, документларын кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гамәлгә ашырыла:

1) гариза һәм документларны кабул итү – 15 минут эчендә;

2) гаризаны теркәү – гариза кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән гариза һәм документлар яисә гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Башкарма комитет Җитәкчесе гаризаны һәм документларны карап тикшерә һәм аларны карап тикшерү өчен идарә башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карап тикшерү өчен идарә башлыгына җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.4. Идарә башлыгы гаризаны, документларны карап тикшерә һәм, карап тикшерү һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен, идарә белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карап тикшерү өчен идарә белгеченә җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.4. Ведомствоара запрослар формалаштыру һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга һәм оешмаларга җибәрү

3.4.1. Идарә белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон формада регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән документларны бирү турында запрос җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: электрон формада җибәрелгән ведомствоара запрослар.

3.4.2. Мәгълүматлар белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән запрослар нигезендә, соралган мәгълүматларны бирә яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле мәгълүматның булмавы турында белдерү кәгазе җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура законда билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: идарә белгеченә җибәрелгән мәгълүматлар яисә мәгълүматлар булмау турында белдерү кәгазе.

3.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү һәм бирү

3.5.1. Идарә белгече алынган мәгълүматлар нигезендә:

1) Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт проектын (алга таба – махсус рөхсәт проекты) яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында белдерү кәгазе (алга таба – баш тарту турында белдерү кәгазе проекты) әзерли;

2) махсус рөхсәт проектын яисә баш тарту турында белдерү кәгазе проектын килештерү өчен идарә башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар ведомствоара запросларга җавап кергән вакыттан башлап ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: идарә башлыгына җибәрелгән махсус рөхсәт проекты яки баш тарту турында белдерү кәгазе проекты.

3.5.2. Идарә башлыгы махсус рөхсәт проектын яисә баш тарту турында белдерү кәгазе проектын карап тикшерә, килештерә һәм махсус рөхсәт проектын имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә яисә баш тарту турында белдерү кәгазе проектын имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура, идарә башлыгы тарафыннан махсус рөхсәт проекты яки баш тарту турында белдерү кәгазе проекты алынган вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән махсус рөхсәт проекты яисе имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына җибәрелгән баш тарту турында белдерү кәгазе проекты.

3.5.3 Башкарма комитет Җитәкчесе махсус рөхсәт проектын имзалый һәм аны теркәү һәм гариза бирүчегә бирү өчен идарә белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган һәм теркәү өчен идарә белгеченә җибәрелгән махсус рөхсәт проекты.

3.5.4 Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары баш тарту турында белдерү кәгазе проектын имзалый һәм, теркәү һәм гариза бирүчегә бирү өчен, идарә белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган һәм теркәү өчен идарә белгеченә җибәрелгән баш тарту турында белдерү кәгазе проекты.

3.5.5. Идарә башлыгы:

1) махсус рөхсәт проектын яки баш тарту турында белдерү кәгазе проектын журналда терки;

2) гариза бирүчегә (аның вәкиленә) гаризада күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә, аны бирү датасын һәм вакытын хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар имзаланган махсус рөхсәт проекты яки баш тарту турында белдерү кәгазе проекты идарә белгеченә кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: теркәлгән махсус рөхсәт яки баш тарту турында белдерү кәгазе.

3.5.6. Идарә белгече гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирә (җибәрә).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гамәлгә ашырыла:

- 15 минут эчендә – гариза бирүче (аның вәкаләтле вәкиле) шәхсән килгән очракта;

- алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә – муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе почта аша җибәрелгән очракта.

Процедураның нәтиҗәсе: бирелгән (җибәрелгән) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе.

3.6. Муниципаль хезмәтне КФҮ аша күрсәтү.

3.6.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану өчен КФҮгә, КФҮнең ерактагы эш урынына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.6.2. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү КФҮнең билгеләнгән тәртиптә расланган эш регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.6.3. Муниципаль хезмәттән файдалану өчен КФҮдән документлар кергәндә, процедуралар әлеге регламентның 3.3 – 3.5 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе КФҮгә җибәрелә.

3.7. Техник хаталарны төзәтү.

3.7.1. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып саналган документта техник хата ачыкланган очракта, гариза бирүче эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә яисә КФҮгә, КФҮнең ерактагы эш урынына түбәндәгеләрне тапшыра:

1) техник хатаны төзәтү турында гариза (регламентка 4 нче кушымта);

2) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсе буларак бирелгән техник хаталы документ;

3) юридик көчкә ия һәм техник хата булуны таныклаучы документлар.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән мәгълүматлардагы техник хатаны төзәтү турында гариза гариза бирүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән, яисә почта аша (шул исәптән электрон почтадан файдаланып); яисә Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша; яисә Татарстан Республикасы Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша; КФҮ, КФҮнең ерактагы эш урыны аша бирелә.

3.7.2. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече теркәлгән документлары белән техник хатаны төзәтү турында гаризаларны кабул итә, гаризаны терки һәм Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән гариза һәм аңа теркәлгән документлар.

3.7.3. Техник хатаны төзәтү турында гариза кергәндә, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатларында регламентның 3.3.3 һәм 3.5 пунктларында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

Идарә белгече техник хата булган документның төп нөсхәсен гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) алгач, шәхсән имза куйдырып, төзәтелгән документны гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) бирә яки почта аша (электрон почта аша) гариза бирүченең адресына, техник хата булган документның төп нөсхәсен идарәгә тапшырган очракта, документны алу мөмкинлеге турындагы хат җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хатаны төзәтү турында гариза теркәлгәннән соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: төзәтелгән һәм гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

## 4. Регламент үтәлешен контрольдә тоту формалары

4.1. Регламент үтәлеше тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерүне, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешенә тикшерүләр үткәрүне, Башкарма комитет вазыйфаи затларының эш итүләренә (эш итмәүләренә) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедуралар үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәгеләр тора:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документ проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

2) эш кәгазьләрен алып баруга билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган тикшерүләр;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлеше буенча билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы (Башкарма комитетның ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырылырга) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр үткәргәндә муниципаль хезмәт күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле, яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык мәсьәләләр каралырга мөмкин.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә эш итүләрне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру максатында Башкарма комитет Җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәләре турында белешмәләр бирелә.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольдә тоту Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла, идарә башлыгы 3 бүлектә күрсәтелгән административ гамәлләрнең үз вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәлмәве өчен җаваплы.

4.3. Үткәрелгән тикшерүләрнең нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартылалар.

4.4. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар ягыннан регламент үтәлешен контрольдә тоту, муниципаль хезмәт күрсәткәндә Башкарма комитет эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм муниципаль хезмәт күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

## 5. Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең, шулай ук КФҮнең, КФҮ хезмәткәрләренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар Башкарма комитетның муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең караларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) Башкарма комитетка, КФҮ хезмәткәрләре буенча – КФҮгә яисә КФҮне гамәлгә куючы гавами-хокукый берәмлекнең дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына судка кадәр шикаять бирергә хокуклы.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросны теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында каралмаган документлар яки мәгълүмат яисә эшләрне гамәлгә ашыруны таләп итү;

4) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) баш тарту өчен нигезләр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының, КФҮнең һәм КФҮ хезмәткәрләренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмаларның яки аларның хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталар һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яки тәртибен бозу;

9) туктату нигезләре федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату;

10) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешнең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, муниципаль хезмәт күрсәтүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү.

5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон формада Башкарма комитетка, күпфункцияле үзәккә яисә КФҮне гамәлгә куючы гавами-хокукый берәмлекнең тиешле дәүләт хакимияте органына (җирле үзидарә органына) бирелә.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, Интернет челтәреннән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтыннан, бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан яисә Татарстан Республикасы бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуыннан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта яки шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылган очракта – ул теркәлгән көннән башлап биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаятьтә булырга тиеш:

1) карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган хезмәт күрсәтүче органның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның җитәкчеләренең һәм (яки) хезмәткәрләренең исеме;

2) гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яшәү урыны турында мәгълүмат яисә гариза бирүче – юридик затның исеме, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең шикаять бирелә торган карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) турында мәгълүмат;

4) гариза бирүченең Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) белән нинди нигездә килешмәвенең дәлилләре.

5.5. Шикаять гариза бирүче яисә аның вәкаләтле заты тарафыннан имзалана.

5.6. Шикаятьне карап тикшерү срогы – ул теркәлгән көннән башлап 15 эш көне эчендә.

Башкарма комитетның, күпфункцияле үзәкнең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмаларның гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуыннан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта яки шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылган очракта – ул теркәлгән көннән башлап биш эш көне эчендә.

5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда Башкарма комитет тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда түләтү каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Регламентның 5.6 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннең икенче көненнән дә соңга калмый, гариза бирүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүченең теләге

буенча электрон формада шикаятьләрне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән җавапта, муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган кимчелекләрне тиз арада бетерү максатында Башкарма комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук тудырылган уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм муниципаль хезмәттән файдалану максатында гариза бирүче башкарырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән җавапта кабул ителгән карар сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.10. Шикаять тулысынча яки өлешчә канәгатьләндерелгән очракта, Башкарма комитет Җитәкчесе кимчелекләрне бетерү максатында кабул ителергә тиешле чараларны билгели.

5.11. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

5.12. Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, шулай ук КФҮнең, КФҮ хезмәткәрләренең карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) гариза бирүчеләр Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт №

| | | | |
|---|---|---|---|
| Йөк ташу төре (җирле) | | Яр Чаллы шәһәре | |
| Башкарырга рөхсәт бирелгән | | Чордагы йөрүләр | |
| Маршрут: | | | |
| Транспорт чарасы (автопоезд) (транспорт чарасының (тягач, прицеп (ярымприцеп) маркасы һәм моделе, транспорт чарасының (тягач, прицеп (ярымприцеп) дәүләт теркәве билгесе | | | |
| Транспорт чарасы хуҗасының исеме, адресы һәм телефоны | | | |
| Йөкнең характеристикасы (исеме, габаритлары, массасы) | | | |
| Транспорт чарасының (автопоездның) параметрлары | | | |
| Йөксез/йөк белән транспорт чарасының (автопоездның) массасы, (т) | | Тягачның массасы (т) | Прицепның (ярымприцепның) массасы (т) |
| | | | |
| Күчәрләр арасындагы ара | | | |
| Күчәрләргә төшкән авырлык (т) | | | |
| Транспорт чарасының (автопоездның) габаритлары | Озынлыгы (м) | Киңлеге (м) | Биеклеге (м) |
| Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты | | | |
| | | | |
| (вазыйфа) | | (имза) | (Фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда) |
| «____» ________________20_____ ел | | М.У. (булганда) | |

| | |
|---|---|
| Озата бару төре | |
| Йөк ташуны килештергән автомобиль юллары, корылмалар, инженерлык коммуникацияләре хуҗалары, Дәүләт автоинспекциясе идарәсе органнары һәм башка оешмалар (килештергән оешманың исеме, килешүнең номеры һәм датасы күрсәтелә) | |
| | |
| А. Россия Федерациясе юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләр ташу өлкәсендәге норматив таләпләр һәм әлеге махсус рөхсәт белән таныштым | |
| Транспорт чарасын йөртүче (ләр) | Дата, имза |
| | |
| Б. Йөк белән/йөксез транспорт чарасы авыр һәм (яки) эре габаритлы йөкләр ташу өлкәсендә әлеге махсус рөхсәттә күрсәтелгән норматив таләпләргә һәм параметрларга туры килә | |
| | |
| Транспорт чарасы хуҗасының имзасы | |
| "__" ___________ 20__ ел | М.У. |
| Транспорт чарасы хуҗасының юл йөрү (юл йөрүләр) турында куйган билгеләре (һәр юл йөрүнең башлану датасы һәм вакыты күрсәтелә, оешманың җаваплы затының имзасы һәм мөһере белән раслана (булганда) | |
| | |
| | |
| Контрольдә тотучы органнар куйган билгеләр (датасы һәм вакыты күрсәтелә) | |
| | |

Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

_______________________________________________________________

_______________________________
(адресатны күрсәтергә: фамилиясе, исеме һәм (булганда) атасының исеме, яшәү урынының адресы (*физик зат өчен)*; гариза бирүченең исеме һәм урнашу урынының адресы (*юридик затлар өчен)*;

Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе

«___»____________20__ ел №___________

Моның белән Сезгә
_______________________________________________________________ сәбәпле
(рөхсәт бирүдән баш тарту нигезен күрсәтергә)
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
(һава киңлегеннән файдалану буенча эшчәнлек төрен күрсәтергә)
башкаруга махсус рөхсәт бирүдән баш тарту турында хәбәр итәбез

___________________ ___________________ ___________________
(вазыйфа) (имза) (имзаның расшифровкасы)

Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
3 нче кушымта

Башкарма комитет Җитәкчесенә

____________________________________________________________________
(Ф.И.А.и.)

____________________________________________________________________

(*физик зат өчен:* гариза бирүченең фамилиясе, исеме һәм (булганда) атасының исеме, яшәү урыны, гариза бирүченең шәхесен раслаучы документ реквизитлары;
*юридик зат өчен*: гариза бирүченең исеме һәм адресы (урнашу урыны), бердәм дәүләт юридик затлар реестрында юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында язманың дәүләт теркәү номеры, почта адресы һәм (яки) гариза бирүче белән элемтә өчен электрон почта адресы)

## Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт алуга гариза

<table>
<tr><td colspan="6">Транспорт чарасы хуҗасының исеме, адресы һәм телефоны</td></tr>
<tr><td colspan="6"></td></tr>
<tr><td colspan="6"></td></tr>
<tr><td>Транспорт чарасы хуҗасының ИНН, ОГРН/ОГРИП</td><td colspan="5"></td></tr>
<tr><td colspan="6">Хәрәкәт маршруты: Рәис Беляев, Хәсән Туфан проспектыннан, Тынычлык проспектыннан, Яр Чаллы проспектыннан (Нариманов урамы белән кисешкән урыннан башлап Академик Королев урамы белән кисешкән урынга кадәр), Муса Җәлил проспектыннан (Үзәк тукталышыннан Поликлиника тукталышына кадәр) тыш, Яр Чаллы шәһәре юллары буенча</td></tr>
<tr><td colspan="6"></td></tr>
<tr><td colspan="4">Йөк ташу төре (регионара, җирле)</td><td colspan="2"></td></tr>
<tr><td>Срогы</td><td>башлап</td><td colspan="2"></td><td>кадәр</td><td></td></tr>
<tr><td>Юлда йөрүләр саны</td><td colspan="5"></td></tr>
<tr><td>Йөкнең характеристикасы:</td><td colspan="2">Бүленә торган</td><td colspan="2">әйе</td><td>юк</td></tr>
<tr><td colspan="3">Исеме <*></td><td colspan="2">Габаритлары</td><td>Массасы</td></tr>
<tr><td colspan="3"></td><td colspan="2"></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="6">Транспорт чарасы (автопоезд) (транспорт чарасының (тягач, прицеп (ярымприцеп) маркасы һәм моделе, транспорт чарасының (тягач, прицеп (ярымприцеп) дәүләт теркәү номеры</td></tr>
<tr><td colspan="6"></td></tr>
</table>

<table>
<tr><td colspan="8">Транспорт чарасының (автопоездның) параметрлары</td></tr>
<tr><td colspan="3" rowspan="2">Йөксез транспорт чарасының (автопоездның) массасы, (т)</td><td rowspan="2"></td><td colspan="3">Тягачның массасы (т)</td><td>Прицепның (ярым-прицепның) массасы) (т)</td></tr>
<tr><td colspan="3"></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="3" rowspan="2"></td><td rowspan="2"></td><td colspan="3"></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="3"></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="3"></td><td></td><td colspan="3"></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="3">Күчәрләр арасындагы ара</td><td></td><td colspan="3"></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="3">Күчәргә төшкән авырлык (т)</td><td></td><td colspan="3"></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="8">Транспорт чарасының (автопоездның) габаритлары</td></tr>
<tr><td>Озынлыгы (м)</td><td colspan="2">Киңлеге (м)</td><td>Биеклеге (м)</td><td colspan="4">Йөк белән борылуның минималь радиусы (м)</td></tr>
<tr><td></td><td colspan="2"></td><td></td><td colspan="4"></td></tr>
<tr><td colspan="4">Озата баручы (саклап баручы) автомобильнең кирәклеге</td><td colspan="4"></td></tr>
<tr><td colspan="6">Транспорт чарасының (автопоездның) күздә тоткан максималь хәрәкәт тизлеге (км/сәг.)</td><td colspan="2"></td></tr>
<tr><td colspan="6">Банк реквизитлары</td><td colspan="2"></td></tr>
<tr><td colspan="8">Түләүне гарантиялибез</td></tr>
<tr><td colspan="2"></td><td colspan="3"></td><td colspan="3"></td></tr>
<tr><td colspan="2">(вазыйфа)</td><td colspan="3">(имза)</td><td colspan="3">(Ф.И.А.и.)</td></tr>
</table>

<*> Графада йөкнең тулы исеме, индивидуаль һәм транспорт тарасының төп характеристикалары, маркасы, моделе, тасвирламасы (беркетү ысулы) күрсәтелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында минем тарафтан күрсәтелгән персональ мәгълүматларны эшкәртүгә һәм тикшерүгә ризалык бирәм.

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен кәгазь документ формасында шәхсән тапшыруны/электрон почта аша электрон документ формасында җибәрүне / «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, электрон документ формасында тапшыруны / телефон аша хәбәр итүне сорыйм (кирәклесенең астына сызарга).

Муниципаль хезмәттән файдалану өчен гаризаны һәм кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карарны кәгазь документ формасында шәхсән тапшыруны/электрон почта аша электрон документ формасында җибәрүне / «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, электрон документ формасында тапшыруны / телефон аша хәбәр итүне сорыйм (кирәклесенең астына сызарга).

Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карарны кәгазь документ формасында шәхсән тапшыруны/электрон почта аша электрон документ формасында

җибәрүне / «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, электрон документ формасында тапшыруны/телефон аша хәбәр итүне сорыйм (кирәклесенең астына сызарга).

| | | |
|---|---|---|
| ________________________ | ____________ | ________________ |
| (число, ай, ел) | (имза) | (расшифровка) |

Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
4 нче кушымта

Башкарма комитет Җитәкчесенә

______________________________________________
(Ф.И.А.и.)

______________________________________________

______________________________

(*физик зат өчен:* гариза бирүченең фамилиясе, исеме һәм (булганда) атасының исеме, яшәү урыны, гариза бирүченең шәхесен раслаучы документ реквизитлары;

*юридик зат өчен*: гариза бирүченең исеме һәм адресы (урнашу урыны), бердәм дәүләт юридик затлар реестрында юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында язманың дәүләт теркәү номеры, почта адресы һәм (яки) гариза бирүче белән элемтә өчен электрон почта адресы)

Техник хатаны төзәтү турында
гариза

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм

______________________________________________
(муниципаль хезмәтнең исеме)

Язылган: ______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

Дөрес мәгълүматлар: ______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып саналган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

Техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кире кагу хакында карар кабул ителгән очракта, андый карарны түбәндәгечә җибәрүне сорыйм:

электрон документны ______________________ электрон почта адресына җибәрү юлы белән;

кәгазьдә расланган күчермә рәвешендә почта аша түбәндәге адреска җибәрүне:

______________________________________________.

Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә (җыюга, системалаштыруга, туплауга, саклауга, аныклауга (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), блокировкалауга, персональ мәгълүматларны юкка чыгаруга, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында персональ мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле булган башка төрле гамәлләргә), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, үземнең ризалыгымны, шулай ук минем тарафтан күрсәтелгән затның ризалыгын раслыйм.

Моның белән раслыйм: әлеге гаризага теркәлгән, минем шәхескә һәм минем тарафтан күрсәтелгән затка кагыла торган, шулай ук түбәндә минем тарафтан кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала.

Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча телефон аша сораштыруда катнашуга ризалыгымны бирәм: ________________________________.

| | | |
|---|---|---|
| ____________________ | ______________________ | ____________________________________ |
| (число, ай, ел) | (имза) | (расшифровка) |

Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында авыр һәм (яки) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
5 нче кушымта

КФҮнең ерактагы эш урыннарының исемлеге

«Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча КФҮ» ДБУ филиалы

1. Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәренең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча КФҮ» МБУ, адресы: Кол Гали бульвары, 25 Е йорт (Яңа шәһәр 59/04);
2. «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча КФҮ» ДБУ Яр Чаллы филиалының өстәмә офисы: Тынычлык проспекты, 62 йорт (Яңа шәһәр 3/16).